РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» декабря 2023г. г. Альметьевск №272

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2022 елның 28 февралендәге 126 номерлы «Әлмәт муниципаль районының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлекләр вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше, Әлмәт муниципаль районы Советының «Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән Әлмәт муниципаль районы территориясендәге җирлекләр вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибе турында» 2015 елның 06 маендагы 468 номерлы карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2022 елның 28 февралендәге 126 номерлы «Әлмәт муниципаль районының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлекләр вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтада:

а) 6 нчы бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Әлеге Килешү рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә һәм 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

6.2. Әлеге Килешү 2024 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6.3. Әгәр дә бер як та аны өзү турында хәбәр итмәсә, килешү автомат рәвештә озайтылган дип санала.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының бюджет-

финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Грушин А.И.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов